КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОШТОРМА-ЮМЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

20 февраль 2019 ел №4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы 2014 елның 04 февраль № 1 карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2018 нче елның 03 нче августындагы № 342-ФЗ Федераль законнарына ярашлы рәвештә «Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым законнар актынаүзгәрешләр кертү турында», 2018 нче елның 03 нче августындагы № 340-ФЗ Федераль законнарына ярашлы рәвештә «Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым законнар актына үзгәрешләр кертү турында» таләпләренә туры китереп, Ошторма-Юмья авыл җирлеге **карарга килде**:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы 04.02.2014 елның № 1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче статьяның унынчы абзацындагы «капиталь ремонт» дигән сүздән соң «җимерү» дигән сүзне өстәргә;

1.2. 26 нчы статьяның 8 нчепунктындагы 2нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексындагы 48 нче статьяның 13 нче өлешендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, капиталь төзелеше объектларының проект документлар составына түбәндәге бүлекләр кертелә:

1) архитектура-төзелеш проектлау, төзелеш, реконструкция, капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләре, инженерлык-техник тәэминат челтәрләренәтоташтыру (технологик тоташтыру) техник шартлары белән һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза үткәрү очрагында проект документларына экспертиза үткәрүгә кадәр аңлатма язуы;

2) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган планлаштыру оешмасы схемасы, ә территорияне планлаштыру проекты нигезендә эшләнгән проект документациясе әзер булган очракта (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булмаган

очраклардан тыш) сызыклы объектларга бүлеп бирелгән полоса проекты проект документларын әзерләү таләп ителми;

3) архитектура, функциональ-технологик, конструктив, инженер-техник чишелешләр һәм (яки) үтәүне тәэмин итүгә юнәлтелгән чараларны үз эченә алган бүлекләр:

а) техник регламентларның, шул исәптән механик, янгын куркынычсызлыгы һәм башка иминлек таләпләренең энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренең, биналар, төзелмәләрнең, корылмаларның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин ителеше таләпләренең (шул исәптән алар составына керә торган челтәрләргә һәм инженерлык-техник тәэминат системаларына), капиталь төзелеш объектына инвалидларның керә алуын тәэмин итү таләпләренең (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял итү, спорт һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә объектларына, транспорт объектларына, җәмәгать туклануы объектлары, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектлар, торак фонды объектлары) ;

б) санитар-эпидемиологик таләпләр, әйләнә-тирә мохитнне саклау өлкәсендәге таләпләр, атом энергиясен куркынычсыз куллануга таләпләр, Сәнәгать куркынычсызлыгы таләпләре, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләр, объектларның террорчылыкка каршы якланганлыгы таләпләре;

в) биналарны һәм корылмаларны проектлау, төзү, монтажлау, көйләү, эксплуатацияләү процессларына карата таләпләр;

г) инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә капиталь төзелеш объектларын тоташтыру (технологик тоташтыру) техник шартлары таләпләре;

4) капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проекты;

5) капиталь төзелеш объектларын куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итүгә таләпләр;

6) мондый объектны куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итү өчен кирәкле капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруның норматив вакытлылыгы, шулай ук күпфатирлы йортны төзү, реконструкцияләү өчен проект документларын әзерләгән очракта күрсәтелгән эшләрнең күләме һәм составы турында мәгълүматлар».

1.3. 26 нчы статьяның 8 нче пунктындагы 15 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проект документларына экспертиза уткәрүгә һәм Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарына тапшырыла торган проект документларының бүлекләрен эчтәлегенә карата таләпләр һәм составы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линия объектларына) карата, шулай ук Капиталь төзелеш объектларының, эш төрләре (капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонт) билгеләнүенә, аларның эчтәлегенә, эшләрен финанслау чыганакларына һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 нче статьясы таләпләренә туры китереп үзгәртеп коруның аерым этаплары

бүлеп биргүгә бәйле рәвештә һәм түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып дифференциацияләнә:

1) проект документларын әзерләү капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линия объектларына) карата аерым бүлекләр күләмендә, шулай ук төзүче яки техник заказчының капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә башкарыла торган эшләрнең эчтәлегенә карап проектлауга йөкләмәсе нигезендә (капиталь төзелеш объектын үзгәртеп корганда) гамәлгә ашырыла;

2) капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проектында капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проекты булырга тиеш (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен төзү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү өчен сүтәргә кирәк булган очракта);

3) проект документларында булган карарлар һәм чаралар мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килергә тиеш ( мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкару өчен проект документлары әзерләнгән очракта, алар мондый объектларның конструктив һәм ышанычлылыгы һәм иминлегенең башка характеристикаларына кагылалар);

4) проект документлары “Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтка, сүтүгә сметалар” бүлеген кертергә тиеш (Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8_3 статьясындагы 2 нче өлешендә күрсәтелгән юридик затлар акчаларын җәлеп итеп финанслана, капиталь ремонт Россия Федерациясебюджет системасы бюджетлары акчаларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8_3 статьясындагы 1 нче өлешендә күрсәтелгән затларның акчаларын җәлеп итеп финанслanса);

5) «куркыныч житештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында»1997 нче елның 21 нче июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясындагы 3 нче пунктында, “Гидротехник корылмаларның куркынычсызлыгы турында” 1997нче елның 21 нче июлендәге117-ФЗ номерлы Федераль законның 10 нчы статьясында , “Атом энергиясеннән файдалану турында” 1995 нче елның 21 нче ноябрендәге 170-ФЗ номерлы Федераль Законның 30 нчы маддәсендә, “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында” 2002 нче елның 25 нче июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 36 нчы маддәсендәге 2 нче һәм 3 нче пунктларында каралган очракларда мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), федераль законнарда каралган документлар, проект документларының бүлекләре мәҗбүри рәвештә проект документлары составына кертелә.

1.4. 25 нче маддәнең 2 нче пунктында “гараж төзелеше” сүзләрен “гараж төзү, реконструкцияләү”, “бакчачылык, дача хуҗалыкларын алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә төзелешләр” сүзләрен “бакча кишәрлекләрендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләү” сүзләре белән алмаштырырга;

1_1 пункты астында түбәндәге эчтәлекне өстәргә:
"1_1) индивидуаль торак төзелеш обьектларын төзү, реконструкцияләү;"

1.5. 26 нчы маддәнең 1 нче пунктында 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Проект документациясен әзерләүне башкару төзелештә, индивидуаль торак төзелеше обьектларын, бакча йортын реконструкцияләүдә таләп ителми. Төзүче үз инициативасы белән индивидуаль торак төзелеше обьектларын, бакча йортын реконструкцияләүгә проект документациясен әзерлеген тәэмин итәргә хаклы".

1.6. 26 нчы маддә 8 нче пункт:

7 нче пункт астында "яки сүтүгә" һәм "яки сүтүне" сүзләрен төшереп калдырырга; 10 нчы пункт астында "капиталь ремонт" сүзләреннән соң "күчерү" сүзе белән тулыландырырга;

1.7. 2 нче маддәнең 4 нче пунктында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә экспертиза нәтиҗәсе булып, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламент таләпләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында бәяләмә тора.

Проект документларына экспертиза нәтиҗәсе булып бәяләмә тора:

1) Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 5өлешенең 1 пунктында каралган таләпләргә (Россия Федерациясе шәһәр төзелешекодексының 49 маддәсендәге 3.3өлешенендокументларына экспертиза үткәрү очракларыннан тыш) яисә проект документларының инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә, проектлау өченбиремгәтуры килү (уңай бәяләмә) яки (тискәре бәяләмә) туры килмәү турында;

2) Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 8.3маддәсе 2 нче өлешендә куелган таләпләр буенча капиталь төзелеш обьектларын төзүнең смета бәясен билгеләүнең туры килү (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында.

1.8. 27 нче маддәнең 8 нче пунктында 3 абзацында "яки индивидуаль торак төзелеше обьекты урнашу урыннарын билгеләү белән җир кишәрлекләрен планлаштыруны оештыру схемалары" һәм "яки җир кишәрлеген планлаштыруны оештыруның күрсәтелгән схемалары" төшереп калдырырга;

27 нче маддәнең 5 нче пунктында 3нче пункт астында 7 нче абзацта "яки сүтүгә" сүзен төшереп калдырырга;

1.9. 28 нче маддәнең 10 нчы пунктында "техник регламентлар" сүзен төшереп калдырырга, "энергетик эффективлылык" сүзеннән соң "(энергетик

эффективлылык таләпләре каралмаган капиталь төзелеш обьектларыннан тыш)" сүзләре белән тулыландырырга;

1.10. 29 нчы маддәнең 5 нче пункты 6 абзацын көчен югалткан дип санарга;

1.11. 30 нче маддәнең 8 нче пунктын "күчемсез милек Бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүче дәүләт мәгълүмат системасында торган мәгълүматларга, документларга һәм материалларга" сүзләре белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының www.pravo.tatarstan.ru хокукый информация официаль порталында чыгарырга һәм махсус информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар, 4 нче пунктта көченә керүнең башка вакыты куелган нигезләмәләрдән тыш, рәсми бастырылган көненнән көченә керә.

4. Әлеге карарның 1.2, 1.3 пунктлары 2019 нчы елның 1 июленнән көченә керә.

Осторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы А.Н. Рамазанов